СОВЕТ НИЖНЕСУНЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.К.Маркса, д.18а, с. Нижняя Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422158

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН СОН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
К.Маркс ур., 18а нче йорт, Түбән Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422158

тел.(факс): (85563) 3-01-41; e-mail: NSun.Mam@tatar.ru, www:mamadнsh.tatarstan.ru

---

**Решение** **Карар**

**“28”марта 2023 г.** **№ 3-24**

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләренә туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Түбән Сон авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбән Сон авыл җирлеге Советының 2022 елның 15 августындагы 2-16 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 3 статьясының 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1 нче кушымтаның 18 статьясының 1пунктындагы “б” пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2. Түбән Сон авыл җирлеге Советының 2016 елның 03 мартындагы 1-6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 1 нче кушымтаның 11.9. пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;».

3. Түбән Сон авыл җирлеге Советының 2020 елның 22 июнендәге 2-54 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш

муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып бирү артык зур булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1. Кушымтаның 3 пунктының 2 абзацында, 4 пунктта, 5 пунктның 2 абзацында, 6 пунктның 1 абзацында, 7 пунктның 1 һәм 3 абзацларында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3.2. Кушымтаның 11 пунктынның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;».

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Түбән Сон
авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе Р.Ш.Гафиятуллин